**Казан шәһәре Башкарма комитетының**
**2024 елның 22 ноябрендәге 4770 номерлы карары**

# Казан шәһәре Башкарма комитетының 2018 елның 3 июлендәге 3854 номерлы «Казан шәһәре муниципаль белем бирү оешмалары хезмәткәрләренең хезмәте өчен түләү шартлары турында»гы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Казан шәһәре муниципаль учреждениеләре хезмәткәрләренең хезмәте өчен түләүне җайга сала торган муниципаль норматив хокукый актларны Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2018 елның 31 маендагы 412 номерлы «Татарстан Республикасы дәүләт белем бирү оешмалары хезмәткәрләренең хезмәте өчен түләү шартлары турында»гы карарына (2018 елның 31 октябрендәге 965 номерлы, 2018 елның 29 декабрендәге 1262 номерлы, 2019 елның 6 маендагы 380 номерлы, 2019 елның 28 августындагы 714 номерлы, 2019 елның 2 ноябрендәге 1008 номерлы, 2019 елның 30 декабрендәге 1278 номерлы, 2020 елның 16 апрелендәге 294 номерлы, 2020 елның 21 маендагы 413 номерлы, 2020 елның 1 сентябрендәге 772 номерлы, 2020 елның 23 октябрендәге 954 номерлы, 2021 елның 26 июлендәге 645 номерлы, 2021 елның 6 сентябрендәге 821 номерлы, 2021 елның 29 октябрендәге 1021 номерлы, 2021 елның 30 октябрендәге 1030 номерлы, 2022 елның 15 июнендәге 566 номерлы, 2022 елның 22 сентябрендәге 1027 номерлы, 2023 елның 11 мартындагы 232 номерлы, 2023 елның 19 августындагы 989 номерлы, 2023 елның 16 октябрендәге 1312 номерлы, 2023 елның 31 октябрендәге 1377 номерлы, 2023 елның 7 ноябрендәге 1431 номерлы, 2024 елның 11 маендагы 318 номерлы, 2024 елның 24 июнендәге 454 номерлы, 2024 елның 25 сентябрендәге 830 номерлы карарлар белән кертелгән үзгәрешләрне һәм

өстәмәләрне исәпкә алып) туры китерү максатыннан **карар бирәм**:

1. Казан шәһәре Башкарма комитетының 2018 елның 3 июлендәге 3854 номерлы «Казан шәһәре муниципаль белем бирү оешмалары хезмәткәрләренең хезмәте өчен түләү шартлары турында»гы карарына (аңа Казан шәһәре Башкарма комитетының 2019 елның 19 мартындагы 869 номерлы, 2019 елның 29 октябрендәге 3921 номерлы, 2022 елның 28 февралендәге 563 номерлы, 2022 елның 6 апрелендәге 962 номерлы, 2023 елның 18 гыйнварындагы 110, 111 номерлы, 2024 елның 9 февралендәге 453 номерлы, 2024 елның 16 сентябрендәге 3906 номерлы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 1 номерлы «Казан шәһәре муниципаль гомуми белем бирү оешмалары хезмәткәрләренең хезмәте өчен түләү шартлары турында нигезләмә» кушымтасында:

1.1.1. II бүлекне түбәндәге редакциядә бирергә:

## «II. Казан шәһәре муниципаль гомуми белем бирү оешмалары хезмәткәрләренең төп окладларын билгеләү

2.1. Казан шәһәре муниципаль гомуми белем бирү оешмалары мәгариф хезмәткәрләренең төп окладлары түбәндәге күләмнәрдә билгеләнә:

| **Квалификация дәрәҗәсе** | **Вазифа атамасы** | **Айлык төп оклад күләме, сум** |
|---|---|---|
| Беренче дәрәҗәдәге уку-укыту буенча ярдәмче персоналның һөнәри квалификация төркеме | | |
| Беренче квалификация дәрәҗәсе | Вожатый | 21473 |
| | Тәрбияче ярдәмчесе | |
| | Уку-укыту часте секретаре | |
| Икенче дәрәҗәдәге уку-укыту буенча ярдәмче персоналның һөнәри квалификация төркеме | | |
| Беренче квалификация дәрәҗәсе | Режим буенча кизү торучы | 21583 |
| | Кече тәрбияче | |
| Икенче квалификация дәрәҗәсе | Мәгариф оешмасы диспетчеры | 21783 |
| | Режим буенча өлкән кизү торучы | |
| Педагогик хезмәткәрләр вазифаларының һөнәри квалификация төркеме | | |
| Беренче квалификация дәрәҗәсе | Хезмәт буенча инструктор | 22663 |
| | Физик культура буенча инструктор | |
| | Музыка буенча җитәкче | |
| | Өлкән вожатый | |
| Икенче квалификация дәрәҗәсе | Концертмейстер | 22758 |
| | Өстәмә белем бирү педагогы | |
| | Педагог-оештыручы | |
| | Социаль педагог | |
| | Тренер-укытучы | |
| | Инструктор-методист | |

| Квалификация дәрәҗәсе | Вазифа атамасы | Айлык төп оклад күләме, сум |
|---|---|---|
| Өченче квалификация дәрәҗәсе | Тәрбияче | 22858 |
| | Җитештерү буенча укыту остасы | |
| | Педагог-психолог | |
| | Өлкән инструктор-методист | |
| | Өстәмә белем бирү буенча өлкән педагог | |
| | Өлкән тренер-укытучы | |
| | Методист | |
| Дүртенче квалификация дәрәҗәсе | Укытучы (профессорлар-укытучылар составына кертелгән укытучы вазифаларыннан тыш) | 22958 |
| | Тормыш куркынычсызлыгы нигезләре буенча укытучы-оештыручы | |
| | Физик тәрбия җитәкчесе | |
| | Укытучы | |
| | Өлкән тәрбияче | |
| | Өлкән методист | |
| | Тьютор (югары һәм өстәмә һөнәри белем бирү өлкәсендә эшләүче тьютордан тыш) | |
| | Укытучы-дефектолог | |
| | Укытучы-логопед (логопед) | |
| | Педагог-китапханәче | |
| Структур бүлекчәләр җитәкчеләре вазифаларының һөнәри квалификация төркеме | | |
| Беренче квалификация дәрәҗәсе | Структур бүлекчә: кабинет, лаборатория, бүлек, бүлекчә, сектор, уку-укыту һәм консультация пункты, уку-укыту (уку-укыту һәм җитештерү) остаханәсе һәм балаларга гомуми белем бирү һәм өстәмә белем бирү программаларын гамәлгә ашыра торган башка структур бүлекчәләр, белем бирү эшчәнлеген методик һәм мәгълүмати-технологик яктан тәэмин итү буенча дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыра торган оешма мөдире (башлыгы) (икенче кваликация дәрәҗәсенә кертелгән структур бүлекчәләр җитәкчеләре вазифаларыннан тыш) | 23008 |
| Икенче квалификация дәрәҗәсе | Балаларга белем бирү программасын һәм өстәмә белем бирү буенча мәгариф программасын гамәлгә ашыра торган аерым структур бүлекчә мөдире (башлыгы), кабинет, лаборатория, бүлек, бүлекчә, сектор, уку-укыту һәм консультация пункты, уку-укыту (уку-укыту һәм җитештерү) остаханәсе, уку-укыту хуҗалыгы һ.б. башлыгы (мөдире, директоры, җитәкчесе, идарәчесе) | 23058 |

2.2. Казан шәһәре гомуми белем бирү оешмалары мәдәният хезмәткәрләренең төп окладлары түбәндәге күләмнәрдә билгеләнә:

| **Вазифа атамасы** | **Айлык төп оклад күләме, сум** |
|---|---|
| «Урта звено мәдәният, сәнгать һәм кинематография хезмәткәрләре вазифалары» һөнәри квалификация төркеме | |
| Аккомпаниатор | 22820 |
| Мәдәни чаралар оештыручы | |
| «Әйдәүче звено мәдәният, сәнгать һәм кинематография хезмәткәрләре вазифалары» һөнәри квалификация төркеме | |
| Китапханәче | 23320 |
| Тавыш операторы | |
| Әйдәүче китапханәче | |
| Рәссам-декоратор | |
| Баш китапханәче | |
| «Мәдәният, сәнгать һәм кинематография учреждениеләренең җитәкче составы вазифалары» һөнәри квалификация төркеме | |
| Китапханәнең бүлек (сектор) мөдире | 24520 |
| Музей бүлеге (секторы) мөдире | |

2.3. Казан шәһәре муниципаль гомуми белем бирү оешмалары медицина хезмәткәрләренең төп окладлары түбәндәге күләмнәрдә билгеләнә:

| **Квалификация дәрәҗәсе** | **Вазифа атамасы** | **Айлык төп оклад күләме, сум** |
|---|---|---|
| «Беренче дәрәҗәдәге медицина һәм фармацевтика персоналы» һөнәри квалификация төркеме | | |
| Беренче квалификация дәрәҗәсе | Авыруларны карау буенча кече шәфкать туташы | 21200 |
| «Урта медицина һәм фармацевтика персоналы» һөнәри квалификация төркеме | | |
| Беренче квалификация дәрәҗәсе | Дәвалау физкультурасы буенча инструктор | 22121 |
| Икенче квалификация дәрәҗәсе | Диета буенча шәфкать туташы | 22621 |
| Өченче квалификация дәрәҗәсе | Шәфкать туташы | 23121 |
| | Физиотерапия буенча шәфкать туташы | |
| | Массаж буенча шәфкать туташы | |
| Дүртенче квалификация дәрәҗәсе | Фельдшер | 23821 |
| | Процедуралар буенча шәфкать туташы | |
| Бишенче квалификация дәрәҗәсе | Өлкән шәфкать туташы | 24821 |
| | Сәламәтлек пункты мөдире – фельдшер (шәфкать туташы) | |
| «Табиблар һәм провизорлар» вазифалары һөнәри квалификация төркеме | | |
| Икенче квалификация дәрәҗәсе | Табиб-белгечләр (өченче һәм дүртенче квалификация дәрәҗәләренә кертелгән табиб-белгечләрдән тыш) | 26521» |

1.1.2. VIII бүлектә:

1.1.2.1. 8.5 пунктның 16 таблицасын түбәндәге редакциядә бирергә:

«16 таблица

**Җитәкчеләрнең хезмәте өчен түләү буенча төркем,
муниципаль гомуми белем бирү оешмалары җитәкчеләренең төп окладлары һәм башкара торган эшләренең сыйфаты өчен стимуллаштыру характерында түләүләр күләме**

| **Җитәкченең хезмәте өчен түләү буенча төркем** | **Күләм күрсәткече зурлыгы (уку елы башына укучылар, тәрбияләнүчеләр саны), кеше*** | **Төп оклад, сум** | **Башкарыла торган эшләрнең сыйфаты өчен стимуллаштыру характерында түләүләр, сум** |
|---|---|---|---|
| 1 | 1-15 | 30000 | 5000 |
| 2 | 16-50 | 32000 | 5000 |
| 3 | 51-100 | 36000 | 6000 |
| 4 | 101-200 | 37000 | 8000 |
| 5 | 201-400 | 40000 | 11000 |
| 6 | 401-600 | 42000 | 11000 |
| 7 | 601-800 | 45000 | 11000 |
| 8 | 801-1000 | 48000 | 11000 |
| 9 | 1001-1200 | 49000 | 13000 |
| 10 | 1201-1400 | 50000 | 14000 |
| 11 | 1401-1800 | 50000 | 17000 |
| 12 | 1801 һәм аннан күбрәк | 51000 | 20000 |

---

*Девиант тәртипле укучылар өчен ябык типтагы гомуми белем бирү оешмаларында, җинаять-үтәтү системасының төзәтү учреждениеләре каршындагы гомуми белем бирү оешмаларында, озак вакыт дәвалануга мохтаҗ балалар өчен шифаханә тибындагы гомуми белем бирү оешмаларында, адаптацияләнгән белем бирү программаларын гамәлгә ашыра торган гомуми белем бирү оешмаларында укучылар контингенты 3 коэффициенты белән исәпкә алына.

Гомуми белем бирү оешмалары каршындагы интернатларда яшәүче укучылар контингенты 2 коэффициенты белән исәпкә алына.

Гомуми белем бирү оешмаларының мәктәпкәчә төркемнәрендә тәрбияләнүчеләр контингенты 1,5 коэффициенты белән исәпкә алына.

Мәктәпара уку-укыту комбинатларында укучылар контингенты 0,5 коэффициенты белән исәпкә алына»;

---

1.1.2.2. 8.10 пунктның дүртенче абзацында «21000» саннарын «22958» саннарына алмаштырырга;

1.2. 2 номерлы «Казан шәһәре муниципаль мәктәпкәчә белем бирү оешмалары хезмәткәрләренең хезмәте өчен түләү шартлары турында нигезләмә» кушымтасында:

1.2.1. II бүлекне түбәндәге редакциядә бирергә:

## «II. Муниципаль мәктәпкәчә белем бирү оешмалары хезмәткәрләренең төп окладларын билгеләү

2.1. Муниципаль мәктәпкәчә белем бирү оешмалары мәгариф хезмәткәрләренең төп окладлары түбәндәге күләмнәрдә билгеләнә:

| **Квалификация дәрәҗәсе** | **Вазифа атамасы** | **Айлык төп оклад күләме, сум** |
|---|---|---|
| Беренче дәрәҗәдәге уку-укыту буенча ярдәмче персонал хезмәткәрләре вазифаларының һөнәри квалификация төркеме | | |
| Беренче квалификация дәрәҗәсе | Вожатый | 21473 |
| | Тәрбияче ярдәмчесе | |
| Икенче дәрәҗәдәге уку-укыту буенча ярдәмче персонал хезмәткәрләре вазифаларының һөнәри квалификация төркеме | | |
| Беренче квалификация дәрәҗәсе | Кече тәрбияче | 21583 |
| Педагогик хезмәткәрләр вазифаларының һөнәри квалификация төркеме | | |
| Беренче квалификация дәрәҗәсе | Физик культура буенча инструктор | 22663 |
| | Музыка буенча җитәкче | |
| Икенче квалификация дәрәҗәсе | Өстәмә белем бирү педагогы | 22758 |
| Өченче квалификация дәрәҗәсе | Тәрбияче | 22858 |
| | Педагог-психолог | |
| | Методист | |
| Дүртенче квалификация дәрәҗәсе | Өлкән тәрбияче | 22958 |
| | Тьютор (югары һәм өстәмә һөнәри белем бирү өлкәсендә эшләүче тьюторлардан тыш) | |
| | Укытучы-дефектолог | |
| | Укытучы-логопед (логопед) | |
| Структур бүлекчәләр җитәкчеләре вазифаларының һөнәри квалификация төркеме | | |
| Беренче квалификация дәрәҗәсе | Структур бүлекчә: кабинет, лаборатория, бүлек, бүлекчә, сектор, уку-укыту һәм консультация пункты, уку-укыту (уку-укыту һәм житештерү остаханәсе) остаханәсе һәм балаларга гомуми белем бирү программасын һәм өстәмә белем бирү буенча мәгариф программасын гамәлгә ашыра торган башка структур бүлекчәләр; белем бирү эшчәнлеген методик һәм мәгълүмати-технологик яктан тәэмин итү буенча дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыра торган оешма мөдире (башлыгы) (икенче кваликация дәрәҗәсенә кертелгән структур бүлекчәләр җитәкчеләре вазифаларыннан тыш) | 23008 |
| Икенче квалификация дәрәҗәсе | Балаларга белем бирү программасын һәм өстәмә белем бирү буенча мәгариф программасын гамәлгә ашыра торган аерым структур бүлекчә мөдире (башлыгы), кабинет, | 23058 |

| Квалификация дәрәҗәсе | Вазифа атамасы | Айлык төп оклад күләме, сум |
|---|---|---|
| | лаборатория, бүлек, бүлекчә, сектор, уку-укыту һәм консультация пункты, уку-укыту (уку-укыту һәм җитештерү) остаханәсе, уку-укыту хуҗалыгы һәм башлангыч һәм урта һөнәри белем бирүче мәгариф учреждениесенең (бүлекчәсенең) башка структур бүлекчәләре башлыгы (мөдире, директоры, җитәкчесе, идарәчесе) (өченче кваликация дәрәҗәсенә кертелгән структур бүлекчәләр җитәкчеләре вазифаларыннан тыш) | |

2.2. Муниципаль мәктәпкәчә белем бирү оешмалары медицина хезмәткәрләренең төп окладлары түбәндәге күләмнәрдә билгеләнә:

| Квалификация дәрәҗәсе | Вазифа атамасы | Айлык төп оклад күләме, сум |
|---|---|---|
| «Беренче дәрәҗәдәге медицина һәм фармацевтика персоналы» һөнәри квалификация төркеме | | |
| Беренче квалификация дәрәҗәсе | Авыруларны карау буенча кече шәфкать туташы | 21200 |
| «Урта медицина һәм фармацевтика персоналы» һөнәри квалификация төркеме | | |
| Беренче квалификация дәрәҗәсе | Дәвалау физкультурасы буенча инструктор | 22121 |
| Икенче квалификация дәрәҗәсе | Диета буенча шәфкать туташы | 22621 |
| Өченче квалификация дәрәҗәсе | Шәфкать туташы | 23121 |
| | Физиотерапия буенча шәфкать туташы | |
| | Массаж буенча шәфкать туташы | |
| Дүртенче квалификация дәрәҗәсе | Фельдшер | 23821 |
| Бишенче квалификация дәрәҗәсе | Өлкән шәфкать туташы | 24821 |
| | Сәламәтлек пункты мөдире – фельдшер (шәфкать туташы) | |
| «Табиблар һәм провизорлар» вазифалары һөнәри квалификация төркеме | | |
| Икенче квалификация дәрәҗәсе | Табиб-белгечләр (өченче һәм дүртенче квалификация дәрәҗәләренә кертелгән табиб-белгечләрдән тыш) | 26521» |

1.2.2. VIII бүлекнең 8.6 пунктындагы 12 таблицаны түбәндәге редакциядә бирергә:

«12 таблица

**Җитәкчеләрнең хезмәте өчен түләү буенча төркем, муниципаль мәктәпкәчә белем бирү оешмалары җитәкчеләренең төп окладлары һәм башкара торган эшләренең сыйфаты өчен стимуллаштыру характерында түләүләр күләме**

| Җитәкченең хезмәте өчен түләү буенча төркем | Күләм күрсәткече зурлыгы (уку елы башына тәрбияләнүчеләр саны), кеше* | Төп оклад, сум | Башкарыла торган эшләрнең сыйфаты өчен стимуллаштыру характерында түләүләр, сум |
|---|---|---|---|
| 1 | 1-20 | 30000 | 5000 |
| 2 | 21-40 | 32000 | 5000 |
| 3 | 41-60 | 36000 | 6000 |
| 4 | 61-80 | 37000 | 7000 |
| 5 | 81-100 | 40000 | 8000 |
| 6 | 101-140 | 42000 | 9000 |
| 7 | 141-180 | 45000 | 10000 |
| 8 | 181-220 | 48000 | 11000 |
| 9 | 221-280 | 49000 | 12000 |
| 10 | 281-320 | 50000 | 13000 |
| 11 | 321-360 | 50000 | 14000 |
| 12 | 361 һәм аннан күбрәк | 51000 | 15000 |

*Адаптацияләнгән белем бирү программаларын гамәлгә ашыра торган мәктәпкәчә белем бирү оешмаларында тәрбияләнүчеләр контингенты 3 коэффициенты белән исәпкә алына.

Туберкулез интоксикациясе булган балалар өчен мәктәпкәчә белем бирү оешмаларында тәрбияләнүчеләр контингенты 2 коэффициенты белән исәпкә алына»;

1.3. 3 номерлы «Казан шәһәре муниципаль өстәмә белем бирү мәгариф оешмалары хезмәткәрләренең хезмәте өчен түләү шартлары турында нигезләмә» кушымтасында:

1.3.1. II бүлекне түбәндәге редакциядә бирергә:

## «II. Муниципаль өстәмә белем бирү оешмалары хезмәткәрләре хезмәт хакының төп окладларын билгеләү

2.1. Муниципаль өстәмә белем бирү оешмаларында мәгариф хезмәткәрләре хезмәт хакының төп окладлары түбәндәге күләмнәрдә билгеләнә:

| Квалификация дәрәҗәсе | Вазифа атамасы | Айлык төп оклад күләме, сум |
|---|---|---|
| Беренче дәрәҗәдәге уку-укыту буенча ярдәмче персоналның һөнәри квалификация төркеме | | |
| Беренче квалификация дәрәҗәсе | Уку-укыту часте секретаре | 21473 |
| Педагогик хезмәткәрләр вазифаларының һөнәри квалификация төркеме | | |
| Беренче квалификация дәрәҗәсе | Хезмәт буенча инструктор | 22663 |
| | Физик культура буенча инструктор | |
| | Музыка буенча җитәкче | |
| Икенче квалификация дәрәҗәсе | Тренер-укытучы | 22758 |
| | Концертмейстер | |

| Квалификация дәрәҗәсе | Вазифа атамасы | Айлык төп оклад күләме, сум |
|---|---|---|
| | Өстәмә белем бирү педагогы | |
| | Педагог-оештыручы | |
| | Социаль педагог | |
| | Инструктор-методист | |
| Өченче квалификация дәрәҗәсе | Җитештерү буенча укыту остасы | 22858 |
| | Педагог-психолог | |
| | Методист | |
| | Өстәмә белем бирү буенча өлкән педагог | |
| | Өлкән тренер-укытучы | |
| | Өлкән инструктор-методист | |
| Дүртенче квалификация дәрәҗәсе | Укытучы (профессор-укытучы составына кертелгән укытучы вазифасыннан тыш) | 22958 |
| | Физик тәрбия җитәкчесе | |
| | Өлкән методист | |
| | Тьютор (югары һәм өстәмә һөнәри белем бирү өлкәсендә эшләүче тьютордан тыш) | |
| Структур бүлекчәләр җитәкчеләре вазифаларының һөнәри квалификация төркеме | | |
| Беренче квалификация дәрәҗәсе | Структур бүлекчә: кабинет, лаборатория, бүлек, бүлекчә, сектор, уку-укыту һәм консультация пункты, уку-укыту (уку-укыту һәм җитештерү) остаханәсе һәм балаларга өстәмә белем бирү буенча мәгариф программасын гамәлгә ашыра торган башка структур бүлекчәләр мөдире (башлыгы) | 23008 |
| Икенче квалификация дәрәҗәсе | Балаларга белем бирү программасын һәм өстәмә белем бирү буенча мәгариф программасын гамәлгә ашыра торган аерым структур бүлекчә мөдире (башлыгы) | 23058 |

2.2. Өстәмә белем бирү оешмаларында авыл хуҗалыгы хезмәткәрләре вазифаларының һөнәри квалификация төркемнәренә караган хезмәткәрләрнең төп окладлары түбәндәге күләмнәрдә билгеләнә:

| Квалификация дәрәҗәсе | Вазифа атамасы | Айлык төп оклад күләме, сум |
|---|---|---|
| Икенче дәрәҗәдәге авыл хуҗалыгы хезмәткәрләре вазифаларының һөнәри квалификация төркеме | | |
| Беренче квалификация дәрәҗәсе | Ветеринария фельдшеры | 22776 |
| Икенче квалификация дәрәҗәсе | Үсемлекләрне саклау буенча урта квалификацияле агроном | |
| Өченче дәрәҗәдәге авыл хуҗалыгы хезмәткәрләре вазифаларының һөнәри квалификация төркеме | | |
| Беренче квалификация дәрәҗәсе | Агроном | 22826 |
| | Зоотехник | |
| | Ветеринария табибы | |
| Икенче квалификация | II категорияле агроном | 22881 |

| Квалификация дәрәҗәсе | Вазифа атамасы | Айлык төп оклад күләме, сум |
|---|---|---|
| дәрәҗәсе | II категорияле зоотехник | |
| | II категорияле ветеринария табибы | |
| Өченче квалификация дәрәҗәсе | I категорияле агроном | 22936 |
| | I категорияле зоотехник | |
| | I категорияле ветеринария табибы | |
| Дүртенче квалификация дәрәҗәсе | Әйдәүче агроном | 22991 |
| | Әйдәүче зоотехник | |
| | Әйдәүче ветеринария табибы | |
| Өченче дәрәҗәдәге авыл хуҗалыгы хезмәткәрләре вазифаларының һөнәри квалификация төркеме | | |
| Беренче квалификация дәрәҗәсе | Баш агроном | 23717 |

2.3. Муниципаль өстәмә белем бирү оешмалары медицина хезмәткәрләренең төп окладлары түбәндәге күләмнәрдә билгеләнә:

| Квалификация дәрәҗәсе | Вазифа атамасы | Айлык төп оклад күләме, сум |
|---|---|---|
| «Урта медицина һәм фармацевтика персоналы» вазифалары һөнәри квалификация төркеме | | |
| Өченче квалификация дәрәҗәсе | Шәфкать туташы | 23121 |
| | Массаж буенча шәфкать туташы | |
| Бишенче квалификация дәрәҗәсе | Өлкән шәфкать туташы* | 24821 |
| «Табиблар һәм провизорлар» вазифалары һөнәри квалификация төркеме | | |
| Икенче квалификация дәрәҗәсе | Табиб-белгечләр (өченче һәм дүртенче квалификация дәрәҗәләренә кертелгән табиб-белгечләрдән тыш) | 26521 |

*Вазифа оешма буйсынуында өч һәм аннан артык шәфкать туташы булган очракта билгеләнә.

2.4. Муниципаль өстәмә белем бирү оешмалары мәдәният хезмәткәрләренең төп окладлары түбәндәге күләмнәрдә билгеләнә:

| Вазифа атамасы | Айлык төп оклад күләме, сум |
|---|---|
| «Урта звено мәдәният, сәнгать һәм кинематография хезмәткәрләре вазифалары» һөнәри квалификация төркеме | |
| Аккомпаниатор | 22820 |
| Костюмнар бүлмәсе мөдире | |
| Мәдәни чаралар оештыручы | |
| «Әйдәүче звено мәдәният, сәнгать һәм кинематография хезмәткәрләре вазифалары» һөнәри квалификация төркеме | |
| Библиограф | 23320 |
| Китапханәче | |
| Әйдәүче китапханәче | |
| Тавыш операторы | |
| Фондларны саклаучы | |
| Рәссам-сынчы | |
| Рәссам-куючы | |

| «Мәдәният, сәнгать һәм кинематография оешмасының җитәкче составы вазифалары» һөнәри квалификация төркеме | |
|---|---|
| Музей бүлеге (секторы) мөдире | 24520» |
| Китапханәнең бүлек (сектор) мөдире | |
| Кино һәм видеофильмнар прокаты бүлеге (пункты) мөдире | |
| Тавыш режиссеры | |
| Режиссер-куючы | |
| Сәнгать җитәкчесе | |

1.3.2. VIII бүлекнең 8.6 пунктындагы 15 таблицаны түбәндәге редакциядә бирергә:

«15 таблица

**Җитәкчеләрнең хезмәте өчен түләү буенча төркем, муниципаль өстәмә белем бирү оешмалары җитәкчеләренең төп оклады һәм башкара торган эшләренең сыйфаты өчен стимуллаштыру характерында түләүләр күләме**

| Җитәкченең хезмәте өчен түләү буенча төркем | Күләм күрсәткече зурлыгы (дәүләт биреме нигезендә уку елы башына белем алучылар саны), кеше | Төп оклад, сум | Башкарыла торган эшләрнең сыйфаты өчен стимуллаштыру характерында түләүләр, сум |
|---|---|---|---|
| 1 | 1-200 | 30000 | 4000 |
| 2 | 201-400 | 32000 | 5000 |
| 3 | 401-700 | 36000 | 5000 |
| 4 | 701-1200 | 37000 | 6000 |
| 5 | 1201-1800 | 40000 | 7000 |
| 6 | 1801 һәм аннан күбрәк | 42000 | 8000» |

1.4. 4 номерлы «Казан шәһәре муниципаль белем бирү оешмаларындагы эшчеләрнең, мәдәният, сәнгать һәм кинематография эшчеләренең гомумтармак һөнәрләре, җитәкчеләрнең, белгечләрнең һәм хезмәткәрләрнең гомумтармак вазифалары һөнәри квалификация төркемнәре хезмәткәрләренең хезмәте өчен түләү шартлары турында нигезләмә» кушымтасындагы II бүлекне түбәндәге редакциядә бирергә:

**«II. Казан шәһәре муниципаль белем бирү оешмаларындагы эшчеләрнең, мәдәният, сәнгать һәм кинематография эшчеләренең гомумтармак һөнәрләре, җитәкчеләрнең, белгечләрнең һәм хезмәткәрләрнең гомумтармак вазифалары һөнәри квалификация төркемнәре хезмәткәрләренең төп окладларын билгеләү**

2.1. Казан шәһәре муниципаль белем бирү оешмаларындагы эшчеләрнең, мәдәният, сәнгать һәм кинематография эшчеләренең гомумтармак һөнәрләре һөнәри квалификация төркемнәре хезмәткәрләренең төп окладлары түбәндәге күләмнәрдә билгеләнә:

| Квалификация дәрәҗәсе | Айлык төп оклад күләме, сум |
|---|---|
| «Беренче дәрәҗәдәге гомумтармак эшче һөнәрләре» һөнәри квалификация төркеме | |
| Беренче квалификация дәрәҗәсе | 21200 |
| Икенче квалификация дәрәҗәсе | 21398 |
| «Икенче дәрәҗәдәге гомумтармак эшче һөнәрләре» һөнәри квалификация төркеме | |
| Беренче квалификация дәрәҗәсе | 21539 |
| Икенче квалификация дәрәҗәсе | 21713 |
| Өченче квалификация дәрәҗәсе | 21891 |
| Дүртенче квалификация дәрәҗәсе | 22422 |

2.2. Казан шәһәре муниципаль белем бирү оешмаларындагы җитәкчеләрнең, белгечләрнең һәм хезмәткәрләрнең гомумтармак вазифалары һөнәри квалификация төркемнәре хезмәткәрләренең төп окладлары түбәндәге күләмнәрдә билгеләнә:

| Квалификация дәрәҗәсе | Айлык төп оклад күләме, сум |
|---|---|
| «Беренче дәрәҗәдәге гомумтармак хезмәткәрләр вазифалары» һөнәри квалификация төркеме | |
| Беренче квалификация дәрәҗәсе | 21200 |
| Икенче квалификация дәрәҗәсе | 21398 |
| «Икенче дәрәҗәдәге гомумтармак хезмәткәрләр вазифалары» һөнәри квалификация төркеме | |
| Беренче квалификация дәрәҗәсе | 21539 |
| Икенче квалификация дәрәҗәсе | 21713 |
| Өченче квалификация дәрәҗәсе | 21891 |
| Дүртенче квалификация дәрәҗәсе | 22118 |
| Бишенче квалификация дәрәҗәсе | 22304 |
| «Өченче дәрәҗәдәге гомумтармак хезмәткәрләр вазифалары» һөнәри квалификация төркеме | |
| Беренче квалификация дәрәҗәсе | 22494 |
| Икенче квалификация дәрәҗәсе | 22687 |
| Өченче квалификация дәрәҗәсе | 22884 |
| Дүртенче квалификация дәрәҗәсе | 23085 |
| Бишенче квалификация дәрәҗәсе | 23311 |
| «Дүртенче дәрәҗәдәге гомумтармак хезмәткәрләр вазифалары» һөнәри квалификация төркеме | |
| Беренче квалификация дәрәҗәсе | 24223 |
| Икенче квалификация дәрәҗәсе | 24423 |
| Өченче квалификация дәрәҗәсе | 24623 |

2.3. Хезмәткәрнең вазифасы һәм һөнәре эшчеләрнең, мәдәният, сәнгать һәм кинематография эшчеләренең гомумтармак һөнәрләре, җитәкчеләрнең, белгечләрнең һәм хезмәткәрләрнең гомумтармак вазифалары һөнәри квалификация төркемнәренең квалификация дәрәҗәләренә туры килүе Россия Федерациясе Сәламәтлек саклау министрлыгының норматив хокукый актлары нигезендә кабул ителә.

2.4. Берьюлы ике эштә, шулай ук тулы булмаган эш вакыты шартларында эшләүче хезмәткәрләрнең хезмәте өчен түләү эшләнгән вакытка пропорциональ рәвештә яки башкарылган эш күләменнән чыгып гамәлгә ашырыла.

Төп вазифа, шулай ук берьюлы башкару тәртибендә биләгән вазифа буенча хезмәт хакы күләмен билгеләү һәр вазифа буенча аерым башкарыла».

2. Әлеге карар 2025 елның 1 гыйнварыннан гамәлгә керә дип билгеләргә.

3. Әлеге карарны «Муниципаль хокукый актлар һәм башка рәсми мәгълүмат» челтәр басмасында (www.docskzn.ru) бастырырга һәм Казан шәһәре җирле үзидарә органнарының рәсми порталында (www.kzn.ru), Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Казан шәһәре Башкарма комитеты Җитәкчесе урынбасары Г.Р.Сәгыйтовага йөкләргә.

**Җитәкче вазифаларын башкаручы –**
**беренче урынбасар** **А.Р.Нигъмәтҗанов**